Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий Урай авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 9**

Троицкий Урай ав. 21.09.2018 ел

Троицкий Урай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 маддәсе 1 өлешенең 1 пунктына, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсендәге 1 пунктының “в” пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Троицкий Урай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 19 сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” гы 12 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” гы 12 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“2018 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Троицкий Урай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешесеннән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыйналган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтүгә ризамы?:

-Троицкий Урай авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тотуга;

- Троицкий Урай авылында балалар мәйданчыгы урнаштыруга;

-Троицкий Урай авыл җирлеге территориясендә зиратларны төзекләндерүгә.

ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Троицкий Урай авылы, Прикамская урамы, 9 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Гремячка авылы, Александров урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий Урай авыл җирлеге
Башлыгыурынбасары Т.А.Емельянова